КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 июнь г.Казань № 538

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 май, 374 нче, 2020 ел, 17 май, 398 нче, 2020 ел, 23 май, 420 нче , 2020 ел, 03 июнь, 465 нче, 2020 ел, 06 июнь, 471 нче, 2020 ел, 17 июнь, 497 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2020 ел, 10 май, 374 нче;

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 17 май, 398 нче;

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2020 ел, 23 май, 420 нче;

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 3 июнь, 465 нче;

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 16 июнь, 471 нче;

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 17 июнь, 497 нче.

3. Әлеге карар 2020 елның 29 июненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карарына 2 нче кушымта

Авырулар исемлеге

1. Эндокрин системасы авыруы – E10 диагнозы буенча 10 (МКБ-10) Авыруларны халыкара классификацияләү нигезендә классификацияләнә торган инсулинга бәйле шикәр диабеты.

2. Сулыш органнары авырулары түбәндәгеләр арасыннан:

2.1. J44 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган башка хроник обструктив үпкә авыруы.

2.2. J45 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган астма.

2.3. J47 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган бронхоэктатик авыру.

3. Кан әйләнеше системасы авыруы – үпкә йөрәге һәм үпкә кан әйләнеше бозылулары, I27.2, I27.8, I27.9 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә.

4. Z94 диагнозы буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнгән трансплантацияләнгән органнар һәм тукымалар булу.

5. Сидек-җенес системасы авыруы* – бөерләрнең 3 – 5 стадиядәге хроник авыруы, 18.0, 18.3 – 18.5 номерлы диагнозлар буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә.

6. Түбәндәгеләрдән шешләр**:

6.1. Теләсә кайсы локализациядәге яман шешләр, шул исәптән C00 – C80, C97 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган мөстәкыйль күп санлы локализацияләрдә.

6.2. Кискен лейкозлар, яманлыгы югары булган лимфомнар, башка лимфопролифератив авыруларның рецидивлары һәм резистент рәвешләре, хроник акселерация һәм бласт кризисы фазаларында хроник миелолейкоз, беренчел хроник лейкозлар һәм лимфомнар* C81 – C96, D46 диагнозлары буенча МКБ-10 нигезендә классификацияләнә торган.

---

* Өченче клиник төркемгә (онкологиядә) кертелгән пациентларга кагылмый.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карары (Татарстан
Республикасы Министрлар
Кабинетының 2020 ел, 27
июнь, 528 нче карары
редакциясендә)

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында

Яңа коронавирус йогышы авыруы таралу куркынычы белән бәйле рәвештә һәм «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 129 номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә яңа коронавирус йогышлы авыруын алып кертү һәм таратуны кисәтү буенча оператив штаб карарларын, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибы карарларын, Татарстан Республикасы буенча Баш дәүләт санитар табибының тәкъдимнәрен (күрсәтмәләрен) гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарәсе органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимы шартларында, чикләү һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Гражданнарга үзизоляцияләү режимын үтәргә, кирәк булмаганда яшәү (тору) урынын калдырып китмәскә, башка гражданнар белән бәйләнешләрне максималь дәрәҗәдә чикләргә киңәш итәргә.

3. Гражданнарның турыдан-туры катнашында ял, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, агарту, реклама һәм башка шундый чаралар үткәрү, шулай ук тиешле хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән мәдәният һәм ял паркларында, сәүдә һәм сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларда), аттракционнарда һәм гражданнар күпләп йөри торган башка урыннарда да рөхсәт ителми дип билгеләргә.

Әлеге чикләү түбәндәгеләргә кагылмый:

музейлар, китапханәләр эшенә, шулай ук 5 кешедән артмаган төркемнәргә экскурсия хезмәтләре күрсәтүгә, ә экскурсиягә хезмәт күрсәтү өчен махсус радиоҗиһазлар булган очракта – 10 кешедән артмаган төркемнәргә;

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары әгъзалары – профессиональ спортчыларның ачык һавада спорт төрләре буенча күнекмәләренә;

бер үк вакытта ике кеше катнашып һәм алар арасында ераклык кимендә 5 метр булган шартларда ачык һавада физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә.

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан яңа коронавирус йогышы авыруы таралу шартларында профилактик чараларны үтәүне тәэмин итә торган формада чаралар оештыру һәм үткәрү рөхсәт ителә.

4. 2020 елның 26 мартыннан башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр кинотеатрлар (кинозаллары), төнге клублар (дискотекалар), балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре һәм башка күңел ачу оешмалары эшчәнлеген туктатып торырга.

5. 2020 елның 28 мартыннан башлап санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр эшне туктатып торырга:

а) сәүдә, сәүдә-күңел ачу үзәкләрендә (комплексларында), ваклап сату базарларында, аларда булган түбәндәгеләрдән тыш:

даруханәләр һәм даруханә пунктлары;

азык-төлек товарлары сатучы ваклап сату объектлары;

урамнан аерым керү урыны булган мобиль элемтә хезмәтләре күрсәтү өчен килешүләр төзү гамәлгә ашырыла торган объектлар;

аерым тышкы (урамнан) керү урыны булган 800 кв. метрга кадәр сәүдә залы мәйданлы азык-төлек булмаган товарлар белән ваклап сату объектлары;

б) башка ваклап сату объектларында, түбәндәгеләрдән тыш:

даруханәләр, даруханә пунктлары;

азык-төлек товарларын ваклап сату объектлары;

транспорт чаралары белән ваклап сату объектлары;

аерым тышкы (урамнан) керү урыны булган 800 кв. метрга кадәр сәүдә залы мәйданлы азык-төлек булмаган товарлар белән ваклап сату объектлары;

в) җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү объектлары, түбәндәгеләрдән тыш:

гражданнарның мондый объектларның бүлмәләренә барып кермичә, заказлар китермичә чыгаруга хезмәт күрсәтү;

гражданнар мондый объектларның бүлмәләренә кермичә, чыгарып бирү, заказларны китереп бирү хезмәтләре күрсәтү;

оешмалар биналарында шул оешмаларның хезмәткәрләренә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү, шулай ук кунакханәләрдә аларда яшәүче затларга җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү;

җәмәгать туклануы объектларының җәйге верандларында һәм стационар террасларында ачык һавада җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү, өстәлләрне 1,5 метр ара дистанцияләүне үтәп урнаштыру шарты белән. Шул ук вакытта стационар җәмәгать туклануы объекты үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу (канализация) системаларына тоташырга тиеш.

Чикләүләр товарларны дистанцион ысул белән сатуга, товарлар китерүгә кагылмый, аларны ирекле сату Россия Федерациясе законнары белән тыелган яки чикләнгән товарлардан тыш.

Әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчалары белән билгеләнгән чикләүләр

Татарстан Республикасы муниципаль районнары территориясендә урнашкан, әлеге карарның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән ваклап сату объектлары эшенә кагылмый.

Әлеге карар нигезендә эшчәнлеге туктатылмаган ваклап сату объектларының эше сәүдә объектының сәүдә залында бер үк вакытта булырга мөмкин булган затларның килүчеләр керә торган сәүдә залының 4 кв.метр мәйданына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) туры килә торган исәпләүдән чыгып билгеләнүче чик санына карата таләпләрне үтәгәндә рөхсәт ителә.

6. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр тыярга:

2020 елның 19 мартыннан башлап оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тарту өчен кальяннар бирү, алар карамагындагы объектларда һәм территорияләрдә кальяннар куллану буенча хезмәтләр күрсәтүне;

2020 елның 01 апреленнән җиңел такси белән бер үк вакытта икедән артык пассажирны (балигъ булмаган затларны исәпкә алмыйча) ташуны;

2020 елның 12 маеннан башлап гражданнарның ваклап сату, хезмәтләр күрсәтү объектларында, гыйбад бүлмәләрендә, биналарында һәм корылмаларында, мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә, пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларында, шул исәптән таксида, сулыш органнарын индивидуаль яклау чараларыннан (битлек, ресираторлар) файдаланмыйча керү һәм булуны;

2020 елның 12 маеннан башлап гражданнарның ваклап сату объектларында, пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларында, шул исәптән таксида, кулларны шәхси саклау чараларын (перчаткалар) кулланмыйча керү һәм булуны;

2020 елның 12 маеннан башлап муниципальара пассажирлар һәм багаж ташуны, даими пассажирлар йөртү маршрутлары буенча пассажирлар һәм багаж ташудан, балалар төркемнәрен балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру оешмасына алып бару һәм алып кайтудан, шулай ук федераль туроператорлар реестрына керә торган юридик зат тарафыннан туристик продуктны гамәлгә ашыру кысаларында ташулардан тыш, пассажирларда маршрут һәм сәфәр датасы турында мәгълүматны да үз эченә алган документлар булганда;

2020 елның 12 маеннан башлап 10 кешедән артык катнашучылар белән никах теркәүне.

7. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр йөкләргә:

2020 елның 30 мартыннан башлап гражданнарга җәмәгать урыннарында, ваклап сату объектларында, хезмәт күрсәтү объектларында, дини бүлмәләрдә, биналарда һәм корылмаларда, мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә, башка гражданнарга 1,5 метрдан да ким булмаган дистанцияне (социаль дистанция) сакларга;

2020 елның 12 маеннан башлап оешмаларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук «Һөнәри керемгә салым" дигән махсус салым режимын кулланучы гражданнарга эшчәнлекләрен оештырганда әлеге карарның 1 нче кушымтасында билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә.

8. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр түбәндәгеләр рөхсәт ителә дип билгеләргә:

а) 2020 елның 05 июненнән башлап спорт җиһазларын социаль дистанцияне тәэмин итеп урнаштыру һәм бер үк вакытта булырга мөмкин затларның чик санына таләпләрне үтәү шарты белән спорт үзәкләренең, йөзү бассейннарының, фитнес-үзәкләрнең эше:

спорт белән шөгыльләнү өчен бүлмәдә – бүлмәнең 4 кв. метрына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган;

төркем белән шөгыльләнү өчен билгеләнгән бассейн зонасында – тиешле зонаның су көзгесе мәйданының 5 кв. метрына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган;

йөзү өчен юллар җиһазландырылган бассейн зонасында – юлның су көзгесе мәйданының 10 кв. метрына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган;

б) 2020 елның 05 июненнән башлап дини оешмалар тарафыннан бер үк вакытта гыйбадәтханә бүлмәсендә, бинасында яки корылмасында булырга мөмкин булган затларның иң чик санына карата таләпләрне үтәүне тәэмин итү шарты белән гыйбадәт бүлмәләренә, биналарына һәм корылмаларына гражданнарның баруы:

мәйданы 400 кв. метрдан артмаган объектларда – бүлмә мәйданының 4 кв. метрына бер кеше (руханиларны һәм хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган;

мәйданы 400 кв. метрдан артмаган объектларда – бер үк вакытта 100 кешедән артмаган (руханиларны һәм хезмәткәрләрне дә кертеп).

в) 2020 елның 08 июненнән башлап Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә Россия Федерациясенең баш дәүләт санитар табибы тарафыннан 2020 елның 20 маенда расланган "COVID-19 таралу куркынычлары саклану шартларында шифаханә-курорт учреждениеләре эшен оештыру буенча тәкъдимнәр" МР 3.1/2.1.0182-20 методик тәкъдимнәрен үтәү турында алдан хәбәр итү шарты белән шифаханә-курорт оешмаларында (санаторийларда) гражданнарны кабул итү һәм урнаштыру;

г) 2020 елның 15 июненнән башлап Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, шул исәптән алдан язылмыйча, бер үк вакытта мәгълүмат бирү һәм көтү секторында әлеге секторның килүчеләр керә алган 4 кв. метр мәйданына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган иң чик санга карата таләпләрне үтәү шарты белән мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү.

9. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганга кадәр 2020 елның 18 июненнән чит ил дәүләтләре территорияләреннән Татарстан Республикасына килгән (кайткан) гражданнарның, шулай ук изоляцияне тәэмин итү чорында күрсәтелгән затлар белән бергә яшәүче гражданнарның яшәү (тору) урыны буенча 14 календарь көн эчендә үзизоляцияләүне тәэмин итүне йөкләргә.

10. Әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән авырулары булган гражданнарга яшәү (тору) урыннарыннан китмәскә киңәш итәргә, түбәндәге очраклардан тыш:

ашыгыч (кичектергесез) медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итүләр һәм тормышка һәм сәламәтлегенә турыдан-туры янау очраклары;

якындагы товарлар сатып алу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр урынына бару;

кешеләр күп була торган урыннарда булмыйча, яшәү (тору) урыныннан 100 метрдан артмаган арада ял итеп йөрү яки йорт хайваннарын йөртү;

калдыкларны якындагы калдыклар җыю  урынына кадәр чыгару;

дистанцион эш формасына күчерү мөмкинлеге булмаган очракта эш урынына бару һәм кире кайту.

65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга яшәү (тору), фактик урнашу урыннарыннан китмәскә, шул исәптән, әлеге пунктның икенче – бишенче абзацларында күрсәтелгән очраклардан тыш, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан торак һәм бакча йортларында да. Күрсәтелгән чикләү 2020 елның 29 июненнән алып  2020 елның 12 июленә кадәр гамәлдә була һәм эш урынында булулары эшләүне тәэмин итү өчен критик мөһим булган оешма һәм хакимият органнары җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә кагылмый.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карарына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы муниципаль районнары исемлеге

1. Әгерҗе муниципаль районы.
2. Аксубай муниципаль районы.
3. Актаныш муниципаль районы.
4. Алексеевск муниципаль районы.
5. Әлки муниципаль районы.
6. Апас муниципаль районы.
7. Арча муниципаль районы.
8. Әтнә муниципаль районы.
9. Балтач муниципаль районы.
10. Югары Ослан муниципаль районы.
11. Биектау муниципаль районы.
12. Чүпрәле муниципаль районы.
13. Кайбыч муниципаль районы.
14. Кама Тамагы муниципаль районы.
15. Кукмара муниципаль районы.
16. Лаеш муниципаль районы.
17. Мамадыш муниципаль районы.
18. Менделеевск муниципаль районы.
19. Минзәлә муниципаль районы.
20. Мөслим муниципаль районы.
21. Яңа Чишмә муниципаль районы.
22. Питрәч муниципаль районы.
23. Балык Бистәсе муниципаль районы.
24. Саба муниципаль районы.
25. Сарман муниципаль районы.
26. Спас муниципаль районы.
27. Тәтеш муниципаль районы.
28. Тукай муниципаль районы.
29. Теләче муниципаль районы.
30. Чирмешән муниципаль районы.
31. Ютазы муниципаль районы.